ГЛАВА КУРНАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ КӨРНӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Коры Көрнәле ав.

**30.10.2020** **№ 3**

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Алексеевск муниципаль районының Көрнәле авыл җирлегенең Коры Көрнәле авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Алексеевск муниципаль районының Көрнәле авыл җирлеге Уставының 23 маддәсе нигезендә

**карар бирәм:**

1. 2020 елның 11 ноябренә 13 сәгать 00 минутта Алексеевск муниципаль районының Көрнәле авыл җирлегенең Коры Көрнәле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Көрнәле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021 елда үзара салым кертүгә сез, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Коры Корнәле авылында урамнарны яктырту (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Коры Көрнәле авылын төзекләндерү (балалар мәйданчыгы территориясен һәм Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга һәйкәл кую һәм аларны урнаштыру өчен төзелеш материаллары сатып алу һәм күчерү, агачларны кисү, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)

ӘЙЕ ЮК».

2. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Алексеевск муниципаль районының Көрнәле авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

3. Җыен үткәрү урыны итеп түбәндәге адрес буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасын билгеләргә: Татарстан Республикасы, Коры Көрнәле авылы, Зәки Кутлин ур., 24 й.

4.Әлеге карарны Көрнәле авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Көрнәле авыл җирлеге башлыгы** **Д.Б.Казакова**